

Дубенка районындагы бердән-бер татар авылы булып яшәгән Ломат авылы турында хәбәрләр язып киләбез; тырыш халкынын матур эшләренә сокланабыз. Булдыра торган халык яши бу авылда. Сvземә дәлил итеп аларнын бvгенге эшләре турында язарга булдым.
Беренчедән, эшне башлар очен бvген теләк, янып йоргән оештыручы-организатор һәм һичшиксез акча булу моһим. Әйтеп китәм, биредә Ломат авылы администрация хезмәткәрләре китереп биргәнне котеп тормыйлар, булганын рациональ кулланып эш итәргә тырышалар.      Мәсәлән, авылнын һәр урамындагы юлларга ремонтны берничә ел жыелып килгән “дорожные” акчасына ясаталар. Тиздән юлларыбыз тәртиптә булыр дип оештыручыларнын берсе булган Раиль хәзрәт Мусин әйтте. Бу эшне Ломат авылы администрациясе эшчеләре белән бергәләп башкаралар.
Раиль хәзрәтне без дин әхеле дип кенә белмибез: ул авылынын патриоты да. Ломаттагы яналыкларнын кvбесе анын коче белән башкарыла. Шулай, vсеп килvче буын вәкилләре, ягъни малайларга футбол уйнарга жайлы булсын дип, футбол мәйданы чистартуны оештырган. Бирелә дә ул эшне авыл администрациясе белән бергә башкара. Чистарту очен бульдозер яллап эшлиләр. Тагы, Ломатка торле жирләрдән якташлары, гаиләләре белән бергә, ялга кайтканнар; рәхәтләнеп алар да уйнасын-нар - бу Раиль хәзрәт сvзләре.
Сvз унаеннан барчабызны борчыган сорауны да бирдем: “Ломатка торле яктан килvчеләр вируслы авырулар алып килмәделәрме?”
- Юк, Аллага шокер кылабыз - авылыбызда авыручыларыбыз юк, - дип жавап кайтарды хәзрәт. - Жәйге ялга авылдашларыбыз кvп килде. - Бергәләшеп печәннен беренче покосын жыйдык, мул иттереп. Ломат администрациябез хезмәткәрләре тирә-яктагы vләннәрне дә чаптырды; матур, чиста, рәхәт булып китте тирә-ягыбыз.
Булдыклы халык яши бу авылда дип юкка гына әйтмәдем: жәй коне, тавык чvпләп бетермәслек эшләр белән бергә, югарыда санап киткәннәрен дә башкарып олгерәләр. Раиль хәзрәт Мусинга килгәндә, ул һәрвакыттагыча яна идеяләр белән янып яши. Әле бу арада, дин әхеле буларак, мәчеттә дин сабак-ларын алып барачак.

**Наилә НАСЫРОВА**